**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Уразай авыл җирлеге Советы**

Уразай авылы №150 «**23**» сентябрь 2019 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Уразай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Уразай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Уразай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләүне киметеп, аны 200 сум (50%) күләмендә билгеләп, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- асфальт түшәмәле юлларның чокырларын ремонтлау Уразай авылы,Речная хэм Подгорная урамнары;
- Уразай авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру;
- Уразай авыл территориясен жыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча жыю, чистарту;
-Уразай авыл халкынын ялын оештыру, бэйрэмнэр үткәрү(Җиңү бәйрәме,сабантуй, балаларны яклау көне,халыкара өлкәннәр көне),
- Уразай авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру;
- Уразай авылында юлларны кардан чистарту;
- Уразай авылында җәй көне территорияне чабу;
-Уразай авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлен ремонтлау;
-Уразай авылында коры агачларны, куакларны кисү, гербицид белән тоташ химик эшкәртү уткэру.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Уразай авылы, Энгельс ур., 65 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Рәис А.М.Шэрифуллина